ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 сентябрь 2026ел № 9544

Башкарма комитетның 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карары белән расланган күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 19 сентябрендәге 4881 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 16 июнендәге 5184 номерлы, 2024 елның 16 февралендәге 1004 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 3755 номерлы, 2024 елның 25 октябрендәге 7077 номерлы, 2024 елның 5 декабрендәге 8132 номерлы, 2025 елның 1 апрелендәге 2466 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган күпфатирлы йорттагы бүлмәне үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрүне килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2 бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 2.19 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«2.19. Аның кысаларында гариза бирүче һәм (яки) гариза бирүчегә караган объектлар һәм (яки) башка объектлар турында мәгълүматларны, шулай ук гариза бирүченең белемнәренең (күнекмәләренең) Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү предметына (дәүләт хезмәте күрсәтү (хезмәт күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) бәяләү үткәрелә торган административ процедураны, гариза бирүчегә карата, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң гамәлгә ашырыла торган, чикләнгән

ресурс (шул исәптән җир участоклары, радиоешлыклар, квоталар) бүлеп бирүне күздә тота торган административ процедураны, гариза бирүчедән өстәмә мәгълүматлар алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк тапкыр кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатуның административ процедурасын гамәлгә ашыру каралмаган.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Гозәеровка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов